РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 39** **2015 елның 4 марты**

# 2015 елның язгы чорында муниципаль юлларда транспорт йөрешен вакытлыча чикләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оешмасының гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы, ТР Министрлар Кабинетының «Региональ яки шәһәрара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яки туктату тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары нигезендә, 2015 елның язында юл өслеге корылмаларының йөк күтәрү сәләте кимүенә бәйле рәвештә, **карар бирәм:**

1. 2015 елның 6 апреленнән 5 маена кадәр чорда Түбән Кама шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенча күчәргә иң чик рөхсәт ителгән йөкләнештән артып киткән транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләү кертергә.

Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чорда җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенча хәрәкәт Түбән Кама шәһәренең автомобиль юлларына салынган зыянны махсус рөхсәтне рәсмиләштереп каплау шарты белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чорга транспорт чарасының һәр күчәренә түбәндәге иң чик рөхсәт ителгән йөкләнешне ласларга:

1) бер күчәрле - 6,0 тонна;
2) ике күчәрле арба - 5,0 тонна;
3) өч күчәрле арба - 4,0 тонна.

3. Әлеге карарның 1 пункты көче түбәндәгеләргә кагылмый дип билгеләргә:

- «Халыкара автомобиль ташуларын гамәлгә ашыруга дәүләт контроле турында һәм аларны үтәү тәртибен бозган өчен җаваплылык хакында» 1998 елның 24 июлендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә башкарыла торган халыкара йөк ташу;
- автобусларда, шул исәптән халыкара пассажирлар йөртү;
- азык-төлек продуктларын, хайваннарны, даруларны, орлык фондын, ашламаларны, почта һәм почта йөкләрен ташу (бу абзацта күрсәтелмәгән йөк белән уртак ташудан тыш);
- ягулык ташучы (бензин, дизель ягулыгы, судно ягулыгы, реактив двигатель ягулыгы, ягу мазуты, газ хәлендәге ягулык) 16 тоннага кадәр йөк күтәрүчәнлекле транспорт чаралары;
- табигать афәтләре яки башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен кирәк булган йөк ташу;

- региональ әһәмияттәге автомобиль юллары өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт юл хәрәкәте куркынычсызлыгы инспекциясе идарәсе һәм җирле әһәмиятле автомобиль юллары өчен җирле үзидарә органнары белән килештерелгән Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы раслаган исемлек нигезендә авария-торгызу һәм ремонт эшләрен башкарганда кулланыла торган юл-төзелеш һәм юл-эксплуатация техникасын һәм материалларны ташу;

- федераль законнар белән хәрби хезмәт каралган федераль башкарма хакимият органнары транспорт чаралары.

4. Түбән Кама шәһәре территориясендәге җаваплы оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләренә тәэмин итәргә (оештырырга):

- Россия Федерациясе законнары нигезендә, әлеге карарның 2 пункты белән билгеләнгән күчәргә йөкләнеш иң чик рөхсәт ителгән йөкләнештән артып киткән йөкле яки йөксез транспорт чараларының Түбән Кама шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итүенә махсус рөхсәтне вакытында бирү;

- Түбән Кама шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын файдаланучыларга Интернет челтәрендә сайтлар, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары аша мондый чикләүләрнең сәбәпләре һәм срогы турында вакытында хәбәр итү;

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чорга региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яки туктатуны гамәлгә ашыру Тәртибе нигезендә тиешле юл билгеләрен өстәмә мәгълүмат билгеләре белән урнаштыру.

5. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт юл хәрәкәте куркынычсызлыгы инспекциясе бүлегенә транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорына юл хәрәкәте куркынычсызлыгын үтәүне контрольдә тотарга һәм авырлык үлчәү постларының урнашу урыннарында дежур торырга тәкъдим итәргә.

6. Кушымта нигезендә вакытлыча рөхсәтнең тәкъдим ителгән бәясен расларга. Түбән Кама шәһәре территориясендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча хәрәкәт иткән өчен зыянны каплау өчен түләнгән акчалар 401 018 108 000 000 10001 исәп-хисап счетына күчерелә дип билгеләргә. Алучы банк - Бүлекчә - Татарстан Республикасының НБ, банкның БИК - 049205001; ИНН - 1651044909; КПП - 165101001; Алучы – ТР буенча УФК («Бюджет һәм финанслар департаменты» МКУ), ОКТМО коды 92644000; бюджет классификациясе коды: 814 113 01 995 05 0000 130 (дәүләт пошлинасын түләү өчен бюджет классификациясе коды: 814 108 071 74 01 1000 110).

7. Әлеге карарны «Нижнекамская Правда», «Туган Як» газеталарында бастырырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

А.Ф.Гәрәев

Түбән Кама шәһәре
башкарма комитеты
җитәкчесенең
2015 елның 4 нче март
39 нчы номерлы карары белән
расланган
1 нче кушымта

**Түбән Кама шәһәре территориясендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча хәрәкәт иткән өчен зыянны каплау исзбенә түләнә торган вакытлы рөхсәт бәясе**

Транспорт чарасының иң чик рөхсәт ителгән массасы кыйммәтеннән арткан очракта зыян күләме

| Транспорт чарасының иң чик рөхсәт ителгән массадан артып китүе (тонна) | Зыян күләме (100 км өчен сум) |
|---|---|
| 5 кә кадәр | 240 |
| 5 тән югары 7 гә кадәр | 285 |
| 7 дән югары 10 га кадәр | 395 |
| 10 нан югары 15 кә кадәр | 550 |
| 15 тән югары 20 гә кадәр | 760 |
| 20 дән югары 25 кә кадәр | 1035 |
| 25 тән югары 30 га кадәр | 1365 |
| 30 дан югары 35 кә кадәр | 1730 |
| 35 тән югары 40 ка кадәр | 2155 |
| 40 тан югары 45 кә кадәр | 2670 |
| 45 тән югары 50 гә кадәр | 3255 |
| 50 дән югары | аерым исәпләү белән <*> |

<*> Зыян күләмен исәпләү, транспорт чарасының иң чик рөхсәт ителгән массасыннан артканда, зыян күләме кыйммәтен математик экстраполяция ысулын кулланып гамәлгә ашырыла.

2 нче таблица

| Транспорт чарасы күчәренә рөхсәт ителгән иң чик күчәр йөкләнешенең артып китүе (процентов) | Пневматик яки аңа эквивалент булган асылма белән җиһазланмаган транспорт чаралары өчен зыян күләме (100 км өчен сум) | Пневматик яки аңа эквивалент булган асылма белән җиһазланган транспорт чаралары өчен зыян күләме (100 км өчен сум) | Табигать һәм климат шартларының начар булуы аркасында вакытлыча чикләүләр чорында зыян күләме (100 км өчен сум) |
|---|---|---|---|
| 10 га кадәр | 925 | 785 | 5260 |
| 10 нан 20 гә кадәр | 1120 | 950 | 7710 |
| 20 дән 30 га кадәр | 2000 | 1700 | 7710 |
| 30 дан 40 ка кадәр | 3125 | 2660 | 10960 |
| 40 тан 50 гә кадәр | 4105 | 3490 | 15190 |
| 50 дән 60 ка кадәр | 5215 | 4430 | 21260 |
| 60 тан югары | аерым исәпләү буенча <*> | | |